ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР**
**25.11.2019**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№2098**

**2020 елга «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүче күпюнәлешле мәгариф оешмаларының һәм туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында**

“Россия Федерациясендә мәгариф турында”, 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 бүлегендәге 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешендәге һәм Татарстан Республикасы балаларына өстәмә белем бирү күпюнәлешле учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында”, 2009 елның 31 декабрендәге 939 номерлы карары һәм “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елга расларга:

беркетелгән «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүче күпюнәлешле мәгариф оешмаларының һәм туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын расларга;

балаларга өстәмә белем бирүче күпюнәлешле мәгариф оешмаларының һәм туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарына карата төзәтү коэффициенты 0,5 күләмендә.

2. “Биектау муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау;

әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә эш хакы индексы белән бер үк вакытта балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнарының гамәлдә булуның барлык чорында яңадан карау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар 2020 елның 1 нчы гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р.Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
«Расланган»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты карары белән
25.11.2019 № 2098

**«Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларына өстәмә белем бирүче күпюнәлешле мәгариф оешмаларының һәм туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль урнашу | Норматив чыгымнар, бер укучыга бер елга, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку еыл | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгати-эстетик | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физик культура-спорт | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экология-биология | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисади | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый-фәнни | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |